КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 май г.Казань № 385

Алексеевск, Яңа Чишмә муниципаль районнарында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 8 нче пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Алексеевск, Яңа Чишмә муниципаль районнарында урнашкан 7,2435 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен кушымта нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 14 май, 385 нче
карарына кушымта

Сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерелә торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар | Муниципаль район исеме |
|---|---|---|
| 16:05:130601:46 | 1,8015 | Алексеевск |
| 16:31:090202:333 | 0,0061 | Яңа Чишмә |
| 16:31:130502:313 | 0,1342 | |
| 16:31:150507:387 | 0,0121 | |
| 16:31:150507:394 | 0,7095 | |
| 16:31:150507:395 | 0,0128 | |
| 16:31:150507:396 | 0,5243 | |
| 16:31:110607:168 | 4,043 | |
| Барлыгы | 7,2435 | |

_______________________________